РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 17 мае 23 номерлы

Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары (Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 14 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары (Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 14 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт үтүгә кагылышлы норматив-хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советы Регламенты, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр
Советының
2019 елның 17 маендагы,
23 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» 6 статьясында:

1) 6.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазыйфалары буенча - ике елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча дүрт елдан да ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – бер елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан ким булмаган эш стажы.»;

2) 6.3 пуктында «өлкән» сүзен «әйдәп баручы, өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

36.4 пунктында «муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен - ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек буенча бер ел эш стажы» сүзләрен «, муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен әзерлек юнәлеше - ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча бер ел эш стажы» сүзләренә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 6.5, 6.6 пунктлары белән тулыландырырга:

«6.5. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен кирәк булган белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре каралган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, әлеге стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрләрнең) белем алу һәм (яки) әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификациясе турында документ алганнан соң әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү чорлары кертелә.

6.6. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе тарафыннан белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралмаган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, әлеге стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрләрнең) аны үтәгәндә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган әлеге дәрәҗәдәге һөнәри белем турында документ алганнан соң, муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча хезмәт вазыйфаларын башкару өчен кирәкле белем һәм осталык алынган эш чоры кертелә.».

2. «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру» 14 статьясында:

1) пунктларны номерлауны «14.1, 14.2, 14.3, 14.3, 14.4, 14.5, 14.6, 14.7, 14.8, 14.9, 14.10» нан «14.1, 14.2, 14.3, 14.4, 14.5, 14.6, 14.7, 14.8, 14.9, 14.10, 14.11» номерлауга алмаштырырга;

2) 14.9 пунктында «14.7 пункты нигезендә» сүзләрен «14.8 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14.10 пунктында «14.9 пункты нигезендә» сүзләрен «14.10 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина